СОВЕТ ДАЧНОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. Дачное, ул. Центральная, 34

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДАЧНЫЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дачный авылы,Үзәк ур., 34

Тел./факс: +7(84365) 78-3-335, e-mail: Dach.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16 апрель 2021 ел.** **№ 26**

## Дачный авыл җирлеге Советының 2021 елның 10 мартындагы 24 номерлы карары белән расланган гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклау Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2021 елның 10 мартындагы 24 номерлы «Гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклау Тәртибен раслау турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Дачный авыл җирлеге Советының 2021 елның 10 мартындагы 24 номерлы карары белән расланган Гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклау Тәртибенә 6 пунктта «башлыкның» сүзен «Башкарма комитетның» сүзенә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Жильцов